# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында"
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында" 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяга түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

"$6^1$) Татарстан Республикасы территориясендә урман янгыннарын сүндерүнең җыелма планын федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы белән килештереп раслау;";

2) 3 статьяда:

а) 2 өлештә:

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10) урман фонды җирләрендә урманнардан файдалануны, аларны саклауны (шул исәптән янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруны һәм урман янгыннарын сүндерүне), яклауны (урман патологиясе мониторингыннан тыш), торгызуны (урман орлыкчылыгыннан тыш) оештыру һәм күрсәтелгән җирләрдә урманнарны саклауны, яклауны, торгызуны (шул исәптән урманнарны саклау, яклау һәм торгызу өчен билгеләнгән урман юлларын булдыруны һәм алардан файдалануны) тәэмин итү;";

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11) дәүләт урман контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеген, урманнарда дәүләт янгын күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү;";

түбәндәге эчтәлекле $11^1$ һәм $11^2$ пунктлар өстәргә:

"$11^1$) республика әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләрендә урнашкан урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруны һәм урман янгыннарын сүндерүне оештыру;

$11^2$) Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрендә урнашкан урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруны оештыру;";

б) 3 өлештә:

11 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"13) урман фонды җирләрендә урманнарда дәүләт урман контролен һәм күзәтчелеген, дәүләт янгын күзәтчелеген, Россия Федерациясе Урман кодексының 81 статьясындагы 36 һәм 37 пунктларында каралган очраклардан тыш, гамәлгә ашыру, шулай ук урман фонды җирләрендә урман төзелешен, Россия Федерациясе Урман кодексының 68 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган очраклардан тыш, башкару;".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 30 июне
№ 35-ТРЗ